РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«26» декабрь 2022 ел          Олы Кайбыч ав.          №164

Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 25 июлендәге 46 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль - хосусый партнерлык турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 25 июлендәге 46 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль - хосусый партнерлык турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 7.1.1 пункт өстәргә:

«7.1.1. Килешүнең мәҗбүри элементлары түбәндәгеләр:

1) хосусый партнер тарафыннан килешү объектын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү (алга таба шулай ук - төзү);

2) хосусый партнерның килешү объектын төзүне тулысынча яисә өлешчә финанславын гамәлгә ашыру;

3) килешү объектын эксплуатацияләүнең һәм (яисә) техник хезмәт күрсәтүнең хосусый партнер тарафыннан гамәлгә ашырылуы;

4) килешү объекты 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән очракта, хосусый партнерда килешү объектына милек хокукы барлыкка килү. »;

түбәндәге эчтәлекле 7.1.2 пункт өстәргә:

«7.1.2. Килешү объектлары түбәндәгеләр:

1) хосусый автомобиль юллары яисә хосусый автомобиль юллары участоклары, күперләр, саклагыч юл корылмалары, ясалма юл корылмалары, җитештерү объектлары (автомобиль юлларын ремонтлаганда, капиталь ремонтлаганда һәм карап тотканда кулланыла торган объектлар), автомобиль

юлларын төзекләндерү элементлары, түләү алу өчен билгеләнгән объектлар (шул исәптән түләү алу пунктлары), юл сервисы объектлары;

2) транспорт инфраструктурасы объектлары һәм, метрополитеннан тыш, аларга технологик бәйле пассажирлар ташуга бәйле эшчәнлекне тәэмин итә торган гомуми файдаланудагы транспорт чаралары;

3) тимер юл транспорты объектлары;

4) торба үткәргеч транспорт объектлары;

5) диңгез портлары, елга портлары, махсуслаштырылган портлар, аларның инфраструктурасы объектлары, шул исәптән федераль милектә булырга мөмкин диңгез порты инфраструктурасы объектларыннан тыш, хосусый милеккә читләштерелергә тиеш булмаган ясалма җир кишәрлекләре, порт гидротехник корылмалары;

6) диңгез суднолары һәм елга суднолары, катнаш (елга - диңгез), йөзү суднолары, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт милкендә булган объектлардан тыш, хосусый милеккә читләштерелергә тиеш булмаган бозваткыч үткәрүне, гидрографик, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы суднолар, паром кичүләре, йөзү һәм коры доклар;

7) дәүләт авиациясе милкенә яисә һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасына кертелгән объектлардан тыш, һава суднолары, аэродромнар, аэропортлар, техник чаралар һәм һава судноларының очышларын тәэмин итү өчен билгеләнгән башка чаралар;

8) электр энергиясен җитештерү, тапшыру һәм бүлү объектлары;

9) гидротехник корылмалар, стационар һәм (яисә) йөзү платформалары, ясалма утраулар;

10) су асты һәм җир асты техник корылмалары, күчешләр, элемтә корылмалары, элемтә һәм коммуникация линияләре, элемтә һәм коммуникацияләрнең башка линия объектлары;

11) сәламәтлек саклау объектлары, шул исәптән сәламәтлек саклау өлкәсендә шифаханә-курорт дәвалануы һәм башка эшчәнлек өчен билгеләнгән объектлар;

12) мәгариф, мәдәният, спорт объектлары, гражданнарның ялын һәм туризмны оештыру өчен кулланыла торган объектлар, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең башка объектлары;

13) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру, җыю, алардан файдалану, зарарсызландыру, урнаштыру, саклау, транспортировкалау, исәпкә алу һәм утильләштерү гамәлгә ашырыла торган объектлар;

14) территорияләрне төзекләндерү объектлары, шул исәптән аларны яктырту объектлары;

15) дәүләт мелиоратив системаларыннан тыш, мелиорация системалары һәм аларның инженерлык инфраструктурасы объектлары;

16) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең, беренчел һәм (яисә) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүнең, саклауның критерийлары нигезендә билгеләнгән объектлары;

17) аучылык инфраструктурасы объектлары;

18) сәнәгать продукциясен җитештерү һәм (яисә) сәнәгать өлкәсендәге башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәти комплекслар;

19) электрон исәпләү машиналары (ЭВМ өчен программалар), мәгълүматлар базалары, мәгълүмат системалары (шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары) һәм (яисә) составына ЭВМ һәм (яисә) белешмәләр базасы өчен шундый программалар кергән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге яисә башка мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар, йә күрсәтелгән объектларның җыелмасы (алга таба - мәгълүмати технологияләр объектлары), йә бер яисә берничә шундый объектка технологик бәйле һәм аларның эшләвен тәэмин итү яисә килешүдә каралган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мәгълүмат технологияләре объектлары һәм мөлкәт (алга таба - мәгълүмати технологияләр объектларының эшчәнлеген техник тәэмин итү чаралары);

20) мәгълүмат технологияләре объектлары белән технологик бәйле күчмә мөлкәткә бердәм билгеләнү белән берләштерелгән һәм ЭВМ өчен программаларны һәм мәгълүматны формалаштыру, саклау, эшкәртү, кабул итү, тапшыру, илтеп җиткерү, мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү, аны тәкъдим итү һәм тарату процесслары күрсәткечләре базаларыннан файдаланып автоматлаштыру өчен билгеләнгән биналар, корылмалар яисә бина өлешләре төркемнәре күплеге;

21) алкоголь, наркотик яисә башка токсик матдәләр белән исерек затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмалар объектлары;

22) хайваннар өчен приютлар урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo. tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе

А.И. Рәхмәтуллин